**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **20 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Камышлы Күл поселогында 2021 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Камышлы Күл поселогында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Камышлы Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү, Камышлы Күл авылында юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү);
- Камышлы Күл авылы урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны ,яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Камышлы Күл поселогында балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл поселогы, Ленин ур., тукталыш янында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.